КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 28 март г.Казань № 182

Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәре авыл җирлегендәге муниципаль хезмәт вазыйфаларына караган кече төркем белгеченең 11 163 сум тәшкил иткән вазыйфаи хезмәт хакы күләменнән чыгып исәпләнә дип билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне (кararга теркәләләр) расларга:

җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициентларын 1 нче кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы шәһәр округлары муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициентларын 2 нче кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасының республика, район әһәмиятендәге шәһәрләре һәм шәһәр тибындагы поселоклары нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре муниципаль

хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициентларын 3 нче кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы авыл җирлекләре муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициентларын 4 нче кушымта нигезендә;

муниципаль берәмлекләр башлыкларының, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге контроль-исәп органнары рәисләренең айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен 5 нче кушымта нигезендә;

муниципаль берәмлекләр башлыкларының, Татарстан Республикасы шәһәр һәм авыл җирлекләрендә җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен 6 нчы кушымта нигезендә.

3. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәре, шулай ук айлык һәм башка өстәмә акча һәм түләүләр күләмнәре арттыру ягына таба бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына чираттагы финанс елына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразын төзегәндә һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре белән бюджетара мөнәсәбәтләрне җайга салганда бу карарның нигезләмәләрен кулланырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2007 ел, 17 декабрь, 722 нче;

«Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен индексацияләү турында» 2007 ел, 28 декабрь, 755 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2007 ел, 17 декабрь, 722 нче карарына теркәлгән 1 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында» 2008 ел, 7 апрель, 215 нче;

«Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларының сайлап куела торган вазыйфаи затларының акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен индексацияләү турында» 2008 ел, 13 октябрь, 745 нче;

«Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларының сайлап куела торган

вазыйфаи затларының акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен индексацияләү турында» 2009 ел, 20 апрель, 253 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2007 ел, 17 декабрь, 722 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 17 декабрь, 1082 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2011 ел, 12 август, 664 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2007 ел, 17 декабрь, 722 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2011 ел, 12 август, 665 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2007 ел, 17 декабрь, 722 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 ел, 21 декабрь, 1030 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2007 ел, 17 декабрь, 722 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 ел, 30 июль, 643 нче;

«Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларының сайлап куела торган вазыйфаи затларының акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен индексацияләү турында» 2012 ел, 1 октябрь, 817 нче;

«Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен индексацияләү турында» 2013 ел, 30 сентябрь, 705 нче;

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларына, депутатларга, җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайлап куелган вазыйфаи затларына, контроль-исәп органнары рәисләренә акчалата түләүләр һәм муниципаль хезмәткәрләргә айлык вазыйфаи окладлары күләмен индексацияләү турында» 2017 ел, 28 июль, 525 нче.

6. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 28 март, 182 нче
карары белән расланды

## Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары

Бу нормативлар бюджетларында соңгы өч хисап финанс елының ике елы дәвамында Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджетларыннан дотацияләр һәм (яки) күчерелә торган акчаның өстәмә нормативлары белән алыштырылган бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең исәпләнә торган күләменнән (дотацияләрнең исәпләнә торган күләме өлешеннән) артыграк булмаган күләмдә күчерелә торган акчаның өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре өлеше җирле бюджетның үз керемнәреннән биш процентка артыграк булган җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнары күләмен билгели.

### I. Гомуми нигезләмәләр

1. Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең айлык акчалата бүләкләү һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәрен билгеләү максатларында, хезмәт өчен түләүнең тиешле муниципаль берәмлек статусыннан һәм аның территориясендә даими яшәүче халык саныннан чыгып түбәндәге төркемнәре бүленә:

1) республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә яки район әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре; шәһәр округлары; республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән һәм составына шәһәр җирлекләре керә торган муниципаль районнар:

беренче төркем – халык саны 1000 мең кешедән артыграк булган муниципаль берәмлекләр;

икенче төркем – халык саны 500 мең кешедән 1000 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләр;

өченче төркем – халык саны 250 мең кешедән 500 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләр;

дүртенче төркем – халык саны 100 мең кешедән 250 мең кешегә кадәр булган

муниципаль берәмлекләр;

бишенче төркем – халык саны 20 мең кешедән 100 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләр;

алтынчы төркем – халык саны 15 мең кешедән 20 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләр;

җиденче төркем – халык саны 15 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләр;

сигезенче төркем – халык санына карамастан башка муниципаль районнар;

2) шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл һәм шәһәр җирлекләре:

тугызынчы төркем – халык саны 10 мең кешедән артыграк булган муниципаль берәмлекләр;

унынчы төркем – халык саны 5 мең кешедән 10 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләр;

унберенче төркем – халык саны 1 мең ярымнан 5 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләр;

уникенче төркем – халык саны 1 мең ярым кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләр.

2. Составына республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге керә торган муниципаль районны хезмәт өчен түләүнең тиешле төркеменә керткәндә әлеге шәһәр җирлеге территориясендә даими яшәүче шәһәр халкы саны гына исәпкә алына.

3. Составына республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге керә торган муниципаль район, бу бүлекнең 1 нче пунктындагы 1 нче пунктча белән күздә тотылганнарга караганда, хезмәт өчен түләү төркемнәренең бер төркеменә югарырак кертеп карала.

## II. Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, Татарстан Республикасы җирле үзидарә депутатларының, сайлап куела торган органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең хезмәте өчен түләү

4. Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең айлык акчалата бүләкләве Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына, депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карарына теркәлгән 5 нче һәм 6 нчы кушымталарда күрсәтелгәннәрдән артмаган күләмдә билгеләнә.

5. Муниципаль берәмлекләр башлыкларына, муниципаль берәмлекләр

башлыклары урынбасарларына, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган органнары әгъзаларына, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренә еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү бер айлык акчалата бүләкләүдән артмаган күләмдә түләнә.

6. Муниципаль берәмлек башлыкларына (шәһәр һәм авыл җирлекләре булып торган һәм хезмәт өчен түләүнең дүртенче – җиденче, тугызынчы – уникенче төркемнәренә кертелгән муниципаль берәмлекләрдән башка), айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, айлык акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр өстәмә түләнергә, шулай ук муниципаль хокук актлары нигезендә башка түләүләр дә башкарылырга мөмкин. Шул ук вакытта тиешле муниципаль берәмлек башлыгына акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләме, түбәндәге чагыштырудан чыгып, Татарстан Республикасының тиешле дәүләт вазыйфасын биләүче затка акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш:

1) беренче төркемгә кертелгән муниципаль берәмлек башлыгына акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләме Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасарына акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш;

2) икенче төркемгә кертелгән муниципаль берәмлек башлыгына акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләме Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарына акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш;

3) өченче – дүртенче төркемнәргә кертелгән муниципаль берәмлекләр башлыкларына акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләме Татарстан Республикасы министрына акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш;

4) сигезенче төркемгә кертелгән муниципаль берәмлекләр башлыкларына акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләме Татарстан Республикасы министрына акчалата түләүләрнең 0,9 айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш.

7. Муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларына (шәһәр һәм авыл җирлекләре булып торган һәм хезмәт өчен түләүнең дүртенче – җиденче, тугызынчы – уникенче төркемнәренә кертелгән муниципаль берәмлекләрдән башка), айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, айлык акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр өстәмә түләнергә, шулай ук муниципаль хокук актлары нигезендә башка түләүләр дә башкарылырга мөмкин. Шул ук вакытта муниципаль берәмлекләре башлыкларының әлеге урынбасарларына акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләме тиешле муниципаль берәмлекләр башлыкларына акчалата түләүләрнең 0,55 айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш.

8. Муниципаль берәмлекләрнең контроль-исәп органнары рәисләренә, айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, айлык акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр өстәмә түләнергә, шулай ук муниципаль хокук актлары нигезендә башка түләүләр дә башкарылырга мөмкин. Шул ук вакытта аларның акчалата түләүләренең айлык җыелма күләме тиешле муниципаль берәмлекләр башлыкларына акчалата

түләүләрнең 0,55 айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш.

9. Шәһәр һәм авыл җирлекләре булып торган муниципаль берәмлекләр башлыкларының һәм аларның урынбасарларының хезмәте өчен түләү шартларын җайга сала торган муниципаль хокук акты белән аларга айлык акчалата бүләкләү түләүне билгеләгәндә айлык акчалата бүләкләүне түләү өлешендә әлеге затларның хезмәте өчен түләү чыгымнары күләме башлыклар өчен – 1 елга унбер айлык акчалата бүләкләүне, аларның урынбасарлары өчен 1 елга сигез айлык акчалата бүләкләүне тәшкил иткән нормативтан артмаска тиеш.

10. Шәһәр һәм авыл җирлекләре булып торган муниципаль берәмлекләр башлыкларының һәм аларның урынбасарларының хезмәте өчен түләү шартларын җайга сала торган муниципаль хокук акты белән тиешле елларны эшләгән өчен айлык бүләкләүгә айлык өстәмә түләү билгеләгәндә өстәмә түләү күләмнәре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларының III бүлегендәге 12 пунктның 2 нче пунктчасында билгеләнгән күләмнәрдән артмаска тиеш. Тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру чыгымнары күләме 1 елга тиешле вазыйфа буенча өч айлык акчалата бүләкләүне тәшкил иткән нормативтан артмаска тиеш.

## III. Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү

11. Муниципаль хезмәткәрләрнең акчалата тулы керемнәре муниципаль хезмәткәрнең үзе билгән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә торган хезмәт хакыннан (алга таба – вазыйфаи хезмәт хакы), тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә түләүдән, муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә түләүдән, аеруча мөһим һәм катлаулы эшләр башкару өчен премияләрдән, айлык акчалата бүләкләүдән, классны чин өчен айлык өстәмә түләүдән, еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән, матди ярдәмнән тора.

12. Муниципаль хезмәткәргә түбәндәгеләр түләнә:

1) вазыйфаи хезмәт хакы;

2) тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә түләү түбәндәгеләрдән артмаган күләмдә:

| Муниципаль хезмәт стажы булганда | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|
| 1 елдан алып 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан алып 10 елга кадәр | 10 |

| | |
|---|---|
| 10 елдан алып 15 елга кадәр | 15 |
| 15 елдан артыграк булганда | 20; |

3) муниципаль хезмәтнең махсус шартлары (катлаулылык, киеренкелек, хезмәттә ирешкән югары казанышлар, махсус эш режимы) өчен җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи хезмәт хакына билгеләнә торган айлык өстәмә түләү түбәндәгеләрдән артмаган күләмнәрдә:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары өчен – вазыйфаи хезмәт хакының 9 процентыннан;

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары өчен – вазыйфаи хезмәт хакының 7 процентыннан;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары өчен – вазыйфаи хезмәт хакының 5 процентыннан;

муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары өчен – вазыйфаи хезмәт хакының 3 процентыннан;

муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары өчен – вазыйфаи хезмәт хакының 1 процентыннан;

4) аеруча мөһим һәм катлаулы эшләр башкару өчен (түләү тәртибе эш бирүче (эш кушучы) вәкиле тарафыннан муниципаль орган бурычларын һәм функцияләрен үтәүне, вазыйфаи тәгълимнамәне үтәүне тәэмин итүне исәпкә алып билгеләнә торган һәм хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә максималь күләм белән чикләнмәгән) премияләр;

5) айлык акчалата бүләкләү вазыйфаи хезмәт хакының 1 процентыннан артмаган күләмдә;

6) классны чин өчен айлык өстәмә түләү түбәндәгеләрдән артмаган күләмдә билгеләнә:

| Классны чин | Классны чин өчен өстәмә түләү күләме, вазыйфаи хезмәт хакына карата процентларда |
|---|---|
| I классны гамәли муниципаль киңәшче<br>I классны муниципаль киңәшче<br>I классны муниципаль хезмәт киңәшчесе<br>I классны муниципаль хезмәт референты<br>I классны муниципаль хезмәт секретаре | 7 |
| II классны гамәли муниципаль киңәшче<br>II классны муниципаль киңәшче<br>II классны муниципаль хезмәт киңәшчесе<br>II классны муниципаль хезмәт референты<br>II классны муниципаль хезмәт секретаре | 5 |
| III классны гамәли муниципаль киңәшче<br>III классны муниципаль киңәшче<br>III классны муниципаль хезмәт киңәшчесе<br>III классны муниципаль хезмәт референты<br>III классны муниципаль хезмәт секретаре | 3; |

7) еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү 1,2 вазыйфаи хезмәт хакыннан артмаган күләмдә;

8) матди ярдәм хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә.

13. Муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары җитәкчеләренең (шәһәр һәм авыл җирлекләре булып торган һәм хезмәт өчен түләүнең дүртенче – җиденче, тугызынчы – уникенче төркемнәргә кертелгән муниципаль берәмлекләрдән тыш) айлык акчалата тулы керемнәре тиешле муниципаль берәмлекләр башлыкларына акчалата түләүләрнең 0,6 айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш.

## IV. Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү фондын формалаштыру

14. Муниципаль районнар, шәһәр округлары, авыл һәм шәһәр җирлекләре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү фондын формалаштырганда вазыйфаи хезмәт хакларын түләү өчен җибәрелә торган акча суммасыннан тыш түләү өчен (1 елга исәпләгәндә 12 вазыйфаи хезмәт хакыннан чыгып) түбәндәге финанс чаралары күздә тотыла:

1) класслы чин өчен айлык өстәмә түләү – вазыйфаи хезмәт хакларының дүрт процентыннан артмаган күләмдә;

2) муниципаль хезмәттә тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә түләү – вазыйфаи хезмәт хакларының унөч процентыннан артмаган күләмдә;

3) муниципаль хезмәтнең махсус шартлары (катлаулылык, киеренкелек, хезмәттә ирешкән югары казанышлар, махсус эш режимы) өчен айлык өстәмә түләү – вазыйфаи хезмәт хакларының биш процентыннан артмаган күләмдә;

4) аеруча мөһим һәм катлаулы эшләр башкару өчен премияләр – вазыйфаи хезмәт хакларының бер процентыннан артмаган күләмдә;

5) еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү – вазыйфаи хезмәт хакларының ун процентыннан артмаган күләмдә;

6) айлык акчалата бүләкләү – вазыйфаи хезмәт хакларының бер процентыннан артмаган күләмдә.

_______________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 28 март, 182 нче
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль районнары
муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәрен
исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициентлары

| Вазыйфа исеме | Өченче төркем* | Дүртенче төркем* | Сигезенче төркем* |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Башкарма комитет җитәкчесе | 3,00 | 2,74 | 2,60 |
| Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары | 2,77 | 2,49 | 2,36 |
| Вәкиллекле орган аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе) | 2,77 | 2,49 | 2,36 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 2,72 | 2,47 | 2,34 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 2,71 | 2,46 | 2,33 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары | 2,46 | 2,25 | 2,14 |
| Башкарма комитет аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе) | 2,52 | 2,31 | 2,19 |
| Башкарма комитет аппараты идарәсе башлыгы | 2,07 | 1,90 | 1,90 |
| Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире), башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе, тикшерү органы аудиторы | 2,06 | 1,82 | 1,82 |
| Башкарма комитет аппараты идарәсе башлыгы урынбасары | 1,86 | 1,80 | 1,80 |
| Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире) урынбасары, башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе урынбасары | 1,70 | 1,59 | 1,59 |
| Муниципаль район башлыгы ярдәмчесе, башкарма комитет | 1,70 | 1,59 | 1,59 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| җитәкчесе ярдәмчесе, муниципаль район башлыгы киңәшчесе, башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе | | | |
| Башкарма комитет идарәсе составындагы бүлек башлыгы | 1,70 | 1,59 | 1,59 |
| Сектор мөдире | 1,58 | 1,49 | 1,47 |
| Баш белгеч | 1,52 | 1,46 | 1,41 |
| Төп белгеч | 1,43 | 1,37 | 1,31 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 1,28 | 1,28 | 1,20 |

* Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 нче пункты нигезендә муниципаль берәмлек керә торган хезмәт өчен түләү төркеме.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 28 март, 182 нче
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы шәһәр округлары муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициентлары

| Вазыйфа исеме | Беренче төркем* | Икенче төркем* |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Башкарма комитет җитәкчесе | 3,59 | 3,26 |
| Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары, вәкиллекле орган аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе), башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 3,51 | 3,16 |
| Башкарма комитет аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе) | 3,42 | 3,08 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 3,41 | 3,07 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе беренче урынбасары, җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары | 3,08 | 2,76 |
| Башкарма комитетының район администрациясе башлыгы | 3,51 | 3,16 |
| Башкарма комитет аппараты җитәкчесе урынбасары (эшләр идарәчесе) | 3,08 | 2,76 |
| Идарә башлыгы, комитет рәисе | 2,62 | 2,30 |
| Идарә башлыгының беренче урынбасары, идарә башлыгы, комитет рәисе урынбасары | 2,35 | 2,12 |
| Башкарма комитетның район администрациясе башлыгы беренче урынбасары, башкарма комитетның район администрациясе башлыгы урынбасары | 2,62 | 2,30 |
| Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире), башка структур бүлекчәсе җитәкчесе, тикшерү органы аудиторы | 2,48 | 2,21 |
| Башкарма комитетның район администрациясе аппараты җитәкчесе | 2,61 | 2,29 |
| Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары, башка структур бүлекчә җитәкчесе урынбасары | 2,10 | 1,82 |
| Башлык ярдәмчесе, башкарма комитет җитәкчесе | 1,84 | 1,78 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| ярдәмчесе, башлык киңәшчесе, башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе | | |
| Идарә, комитет составындагы бүлек башлыгы, башкарма комитетның район администрациясе бүлеге башлыгы | 1,84 | 1,78 |
| Сектор мөдире | 1,81 | 1,73 |
| Башкарма комитетның район администрациясе бүлеге башлыгы урынбасары | 1,81 | 1,73 |
| Баш белгеч | 1,76 | 1,66 |
| Төп белгеч | 1,61 | 1,52 |
| I категорияле белгеч, II категорияле белгеч, белгеч | 1,43 | 1,35 |

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 нче пункты нигезендә муниципаль берәмлек керә торган хезмәт өчен түләү төркеме.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 28 март, 182 нче
карарына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасының республика, район әһәмиятендәге шәһәрләре һәм шәһәр тибындагы поселоклары нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициентлары

| Вазыйфа исеме | Дүртенче төркем* | Бишенче төркем* | Алтынчы – җиденче төркем* | Тугызынчы төркем* | Унынчы төркем* |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Башкарма комитет җитәкчесе | 2,74 | 2,49 | 2,12 | 1,86 | 1,63 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, вәкиллекле орган аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе) | 2,49 | 2,31 | 1,97 | 1,80 | 1,60 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 2,46 | 2,21 | 1,97 | 1,80 | 1,60 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары | 2,25 | 2,03 | 1,90 | 1,67 | 1,42 |
| Башкарма комитет аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе) | 1,90 | 1,73 | 1,72 | - | - |
| Башкарма комитет идарәсе (аппараты) башлыгы | 1,90 | 1,73 | - | - | - |
| Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире), башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе | 1,90 | 1,73 | 1,72 | 1,52 | 1,32 |
| Башкарма комитет идарәсе (аппараты) башлыгы урынбасары | 1,59 | 1,49 | 1,49 | - | - |
| Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире) | 1,59 | 1,49 | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| урынбасары, башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе урынбасары | | | | | |
| Шәһәр җирлеге башлыгы ярдәмчесе, башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе, шәһәр җирлеге башлыгы киңәшчесе, башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе | 1,59 | 1,49 | - | - | - |
| Башкарма комитет идарәсе (аппараты) составындагы бүлек башлыгы | 1,59 | 1,49 | - | - | - |
| Сектор мөдире | 1,49 | 1,30 | - | - | - |
| Баш белгеч | 1,46 | 1,24 | 1,24 | - | - |
| Төп белгеч | 1,37 | 1,17 | 1,17 | 1,17 | 1,11 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 1,27 | 1,05 | 1,05 | 10,5 | 1,00 |

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 нче пункты нигезендә муниципаль берәмлек керә торган хезмәт өчен түләү төркеме.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 28 март, 182 нче
карарына 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы авыл җирлекләре муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициентлары

| Вазыйфа исеме | Тугызынчы төркем* | Унынчы төркем* | Унберенче төркем* | Уникенче төркем* |
|---|---|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 1,86 | 1,63 | 1,50 | 1,37 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (секретарь) | 1,80 | 1,60 | 1,47 | 1,33 |
| Төп белгеч | 1,17 | 1,11 | 1,11 | 1,11 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 1,05 | 1,00 | 1,00 | 1,00 |

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 нче пункты нигезендә муниципаль берәмлек керә торган хезмәт өчен түләү төркеме.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 28 март, 182 нче
карарына 5 нче кушымта

Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге контроль-исәп органнары рәисләренең айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфа исеме | Беренче төркем* | Икенче төркем* | Өченче төркем* | Дүртенче төркем* | Сигезенче төркем* |
|---|---|---|---|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 40 720 | 36 902 | 33 948 | 31 034 | 29 555 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 36 648 | 33 212 | 30 552 | 27 929 | 26 600 |
| Депутатлар | 18 405 | 17 611 | 16 586 | 15 040 | 14 492 |
| Җирле үзидарәнең сайлап куела торган органнары әгъзалары | 15 641 | 14 970 | 14 094 | 12 782 | 12 314 |
| Контроль-исәп органнары рәисе | 36 648 | 33 212 | 30 552 | 27 929 | 26 600 |

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 нче пункты нигезендә муниципаль берәмлек керә торган хезмәт өчен түләү төркеме.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 28 март, 182 нче
карарына 6 нчы кушымта

Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, Татарстан Республикасы шәһәр һәм авыл җирлекләрендә җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

(сум)

| Вазыйфа исеме | Республика һәм район әһәмиятендәге шәһәрләр нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләрендә | | | | Шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл һәм шәһәр җирлекләрендә | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | дүртенче төркем* | бишенче төркем* | алтынчы төркем* | җиденче төркем* | тугызынчы төркем* | унынчы төркем* | унберенче төркем* | уникенче төркем* |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 31 034 | 28 160 | 26 505 | 23 521 | 18 405 | 15 066 | 13 369 | 11 701 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 27 927 | 25 342 | 23 851 | 21 167 | 16 565 | 13 561 | 12 036 | 10 531 |
| Депутатлар | 15 040 | 13 494 | 12 588 | 11 988 | 9 923 | 9 486 | 9 061 | 8 621 |
| Җирле үзидарәнең сайлап куела торган органнары әгъзалары | 12 782 | 11 468 | 10 702 | 10 196 | 8 431 | 8 062 | 7 693 | 7 337 |

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 нче пункты нигезендә муниципаль берәмлек керә торган хезмәт өчен түләү төркеме.